Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Ульяновка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлегенең Сосновка
торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**«25» октябрь 2024 ел** **№ 1/5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 25 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2025 елда Ульяновка авыл җирлегенең Сосновка торак пункты территориясендә теркәлгән һәм дәими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәгеләрдән һәм 90 яшьтән өлкәнрәк булган гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Сосновка торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Сосновка торак пунктында урам яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Сосновка торак пунктындагы су җыю манарасы территориясен, скважиналарны төзекләндерү, су насосларын сатып алу (ремонтлау), суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау);

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Сосновка торак

пунктында урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, 20-30 мм фракциясендәге вак таш сатып алу).

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 104 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 55 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 55 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Сосновка торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2025 елда Ульяновка авыл җирлеге Сосновка торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәгеләрдән һәм 90 яшьтән өлкәнрәк булган гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Сосновка торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

**- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Сосновка торак пунктында урам яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Сосновка торак пунктындагы су җыю манарасы территориясен, скважиналарны төзекләндерү, су насосларын сатып алу (ремонтлау), суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау);

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Сосновка торак пунктында урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, 20-30 мм фракциясендәге вак таш сатып алу) – кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Ульяновка авылы, Центральная урамы, 44 нче йорт, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми интернет сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Ульяновка авыл җирлеге башлыгы С.З. Шәмсетдинов